Ф. Г. Әхмәрова исемендәге 4 нче номерлы балалар поликлиникасы ветераннары.

**Сиразетдинова Ләлә Заһит кызы** С.В. Курашова исемендәге Казан дәүләт медицина институтының «педиатрия» бүлеген тәмамлаган.

Ләлә Заһит кызының барлык хезмәт эшчәнлеге 4 нче номерлы балалар поликлиникасы белән бәйле: 1982 нче елның августында интернатураны тәмамлаганнан соң участок табиб - педиатр булып эшкә урнаша.



1996 нчы елның октябрендә мәктәпкәчә белем бирү бүлеге мөдире вазифасына күчерелә. 1998 нче елның ноябрь аеннан алып 2017 нче елның 4 нче июленә кадәр әлеге сырхауханәдә баш табиб вазифасын үти. Ләлә Заһит кызы, сырхауханәнең дәвалау һәм хуҗалык эшчәнлеге җитәкчелек эшчәнлегеннән тыш, практик эшләүче табиб-педиатр, алты фәнни мәкалә авторы. Россия педиатрлар конгрессына ике тапкыр мәкаләләрен җибәрә һәм Россия педиатрлар берлегенең фәнни - гамәли журналларында мәкаләләре басылып чыга. Үзенә йөкләнгән вазыйфаларына җаваплы карашы һәм оештыру сәләте аркасында, Ләлә Заһит кызы оста җитәкчелек итә, балаларга медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын яхшырту өчен алдынгы методлар кертә. Эш нәтиҗәләре буенча, ул җитәкләгән сырхауханә берничә тапкыр шәһәрнең балалар дәвалау оешмалары арасында иң яхшыларның берсе дип танылды.

Ләлә Заһит кызы үзен медицина өлкәсендә генә түгел, ә җәмәгать эшендә дә актив күрсәтте: ике ел дәвамында Яр Чаллы шәһәре «Бердәм Россия» җирле бүлегенең сәяси совет әгъзасы булды; 1995 нче елдан 2006 нчы елга кадәр шәһәр халык советы депутатлар бердәмлегенең социаль мәсьәләләр буенча сәламәтлек саклау өлкәсендә даими комиссия урынбасары вазифасын үтәде. 30 ел дәвамында Россия педиатрлар берлегенең Яр Чаллы филиалының идарә әгъзалары активисты була.

01.12.2010 нчы елны Л. З. Сиразетдинова җитәкчелегендә, сырхауханәдә балалар өчен Сәламәтлек үзәге ачылды.

Ләлә Заһит кызы Татарстан Республикасының Атказанган табибы. Хәзерге вакытта сырхауханәдә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең табиб-педиатры буларак эшен дәвам итә.

**Пушина Фәйрүзә Галимҗан кызы** 1977 нче елда "дәвалаучы табиб" белгечлеге буенча Ижау дәүләт медицина институтын тәмамлаган. Үзенең хезмәт эшчәнлеген Сарапул шәһәренең балалар шәһәр хастаханәсендә педиатрия буенча табиб-интерн вазыйфаларында башлап җибәрә.



1978 нче елда Яр Чаллы шәһәренә күчеп килә һәм хезмәт эшчәнлеген 2 нче номерлы балалар поликлиникасында участок табиб-педиатр вазыйфасында дәвам итә. ДАССУ "Ф.Г.Әхмәрова исемендәге 4 нче номерлы шәһәр балалар сырхауханәсе"ндә ачылган көннән бирле эшли. 1979 нчы елның апреленнән бирле участок табиб - педиатр вазыйфасын башкара. Фәйрүзә Галимҗан кызы эшләгән участок сырхауханәнең иң яхшы участокларның берсе иде. 1998 нче елның апрель аеннан алып 1998 нче елның июленә кадәр «Сонатал»пренаталь тәрбия кабинеты мөдире булып хезмәт итә. 1998 нче елның июленнән алып бүгенге көнгә кадәр «Сонатал»пренаталь тәрбия кабинетың консультатив-диагностика бүлегендә табиб-педиатр булып эшли.